ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«18» апрель 2022ел №296

**2022 елда югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы терлекчелек предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәне раслау хакында**

Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең алга таба терлекчелек продукциясен җитештерү күләмнәрен үстерү, авыл хуҗалыгы терлекләренең продуктлылыгын һәм сакланышын, авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләренең югары күрсәткечләргә ирешүгә кызыксынуын арттыру максатыннан Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. 2022 елда югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

1.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен ачыклау буенча район комиссиясе составын (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http: pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http: arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Р.М. Гатиятовка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"18" апрель 2022ел,*
*№ 296*
*карарына 1 нче кушымта*

**2022 елда югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә (алга таба-Нигезләмә) Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең терлекчелек продукциясе күләмнәрен арттыру, авыл хуҗалыгы терлекләренең продуктивлыгын һәм сакланышын үстерү, авыл хуҗалыгы оешмалары хезмәткәрләренең югары күрсәткечләргә ирешүдә кызыксынуларын арттыру эшенә нәтиҗә ясау максатыннан эшләнде.

1.2. 2022 елның апреленнән башлап һәр айның 25 числосыннан соң ясалган нәтиҗәләр буенча предприятиеләр буенча да, тулаем район буенча да иң югары күрсәткечләргә ирешкән Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре терлекчелек тармагы хезмәткәрләре бүләкләнә.

1.3. Район комиссиясе (алга таба - комиссия) бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы терлекчелек предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен билгели.

1.4. Җитештерү алдынгыларын билгеләгәндә, комиссия тарафыннан дәгъвачыларның җитештерү күрсәткечләре яисә аларның җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәләренә ирешүгә керткән өлеше исәпкә алына.

1.5. Җиңүчеләрне бүләкләү авыл хуҗалыгы оешмаларының терлекчелек фермаларына барып үткәрелә.

1.6. Оештыручылар- Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе.

1.7. Финанслау Арча муниципаль районы бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла. Барлыгы 51 кеше бүләкләнә, алдынгы терлекчеләрне бүләкләүгә 102 мең сум акча карала.

## 2. Максат һәм бурычлар

2.1. Арча муниципаль районы терлекчелек тармагында терлекчелек продукциясен җитештерүдә иң югары күрсәткечләргә ирешкән алдынгыларны ачыклау.

2.2. Авыл хуҗалыгы оешмалары хезмәткәрләрен иң югары күрсәткечләргә ирешүгә кызыксындыру.

2.3. Терлекчелек тармагы алдынгыларын хезмәт эшчәнлегендә югары күрсәткечләргә ирешүгә рухи һәм матди яктан кызыксындыру.

2.4. Яшь хезмәткәрләрне җәлеп итү максатыннан, авыл хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү.

## 3. Терлекчелек тармагы алдынгыларын бүләкләү тәртибе

3.1. Бүләкләү өчен кандидатуралар алдынгыларның җитештерү күрсәткечләрен, авыл хуҗалыгы оешмасында эш стажын, оешмалар җитәкчеләренең бүләкләү турында үтенечнамәләрен исәпкә алып билгеләнә.

3.2. Хисап аенда иң күп сөт сауган машина белән сыер саву операторары, иң югары артым алган бозау карауучылар яисә терлекчеләр, шулай ук яшь терлекләрнең буазлыгын һәм сакланышын тикшерү нәтиҗәләре буенча эре мөгезле терлекләр үрчетү буенча ветеринария табиблары һәм технологлар бүләкләнә.

3.3. Алдынгыларның барысы да 2000 сумлык акчалата премия һәм Арча муниципаль районы башлыгының рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"18" апрель 2022ел, №296*
*карарына 2 нче кушымта*

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре терлекчелегенең алдынгы хезмәткәрләрен ачыклау буенча район комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Рәис: | |
| Галимуллин И.Ә. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы; |
| Рәис ярдәмчесе: | |
| Гатиятов Р. М. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Секретарь: | |
| Хәйретдинов Р.Р. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районында ПМО консультанты (килешү буенча). |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Галимуллина Г.Х. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы; |
| Абдуллин М. Р. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе ФЭО башлыгы (килешү буенча); |
| Фәйзрахманов Р.Р. | - «Арча РДВБ» ДБУ башлыгы (килешү буенча); |
| Зарифуллина З.М. | - Арча муниципаль районының селекция-нәсел хезмәте башлыгы ( килешү буенча). |